СОВЕТ ТАВЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Нагорная, д.70, с. Тавели,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422160

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАУИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Таү өсте урамы, 70 йорт, Тауиле авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы, 422160

Тел. (факс): (85563) 2-67-25 e-mail: Tavel.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

“10” июня 2021 г. | № 1-9

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге №273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы, нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-7 номерлы карарына Мамадыш районы прокуратурасының 2021 елның 26 маендагы № 02-08-02-2021 протесты нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (18.11.2016 № 2-14, 15.05.2017 № 1-22, 28.07.2017 № 3-23, 14.11.2017 № 2-27, 05.06.2018 № 2-33, 13.08.2018 № 2-35, 20.11.2018 № 3-38, 14.12.2018 № 2-39 21.03.2019 №1-41, 18.09.2019 № 3-46, 19.02.2020 № 1-51, 17.11.2020 № 3-2 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 статьяның 5.15 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турында белешмәләр шәхси эшкә һәм муниципаль хезмәткәрнең хезмәт кенәгәсенә (булганда) кертелә»;

1.2. 7 статьяның 7.4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазифа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмыйлар»;

1.3. 25 статьяның 25.11 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплы итеп Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге башлыгы В.И.Ивановка билгеләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Тауиле авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /В.И.Иванов/